ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№314 от «26» 08 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 7 октябрендәге «Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын яңа редакциядә раслау турында» 331 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында»2024 елның 22 июлендәге 194-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 7 октябрендәге «Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын яңа редакциядә раслау турында» 331 номерлы карары (алга таба – Карар) белән расланган Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта), Муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән муниципаль милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, сатулар үткәрмичә генә түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаның 2.8.2.1 пунктындагы 8-10 пунктчасында «территорияне комплексны үстерү» сүзләреннән соң «яисә, күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплексны үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, аны комплексны үстерү турында карар кабул ителгән» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль районының рәсми http://www.mamadysh.tatarstan.ru сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. . Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы Р.М.Никифоров

0000012325